# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Буа муниципаль районы составына керүче "Аксу авыл җирлеге", "Бик-Үти авыл җирлеге", "Әлши авыл җирлеге", "Кҷушке авыл җирлеге", "Зур Фролово авыл җирлеге" һәм "Түбән Наратбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

"Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 1, № 12 (V өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Буа муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *70(5) - 67(6)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *67(6) - 6(7)* | - Чуаш Республикасы |
| *6(7) - 33(36)* | - Апас муниципаль районы |
| *33(36) - 75(4)* | - Тәтеш муниципаль районы |
| *75(4) - 79(4в)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *79(4в) - 78(4г)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *78(4г) - 70(5)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *71(5а) - 82(5б)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *82(5б) - 71(5а)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *6а (2 участок)* | - Чуаш Республикасы |

Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

"Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Буа шәһәре |
| 2 | Адав-Толымбай авыл җирлеге |
| 3 | Аксу авыл җирлеге |
| 4 | Әлши авыл җирлеге |
| 5 | Алших авыл җирлеге |
| 6 | Бик-Үти авыл җирлеге |
| 7 | Зур Фролово авыл җирлеге |
| 8 | Боерган авыл җирлеге |
| 9 | Югары Лашчы авыл җирлеге |
| 10 | Исәк авыл җирлеге |
| 11 | Кайбыч авыл җирлеге |
| 12 | Кыят авыл җирлеге |
| 13 | Күшке авыл җирлеге |
| 14 | Шәмәк авыл җирлеге |
| 15 | Татар Буасы авыл җирлеге |
| 16 | Карлы авыл җирлеге |
| 17 | Мөкерле авыл җирлеге |
| 18 | Түбән Наратбаш авыл җирлеге |
| 19 | Яңа Тинчәле авыл җирлеге |
| 20 | Яңа Чәчкап авыл җирлеге |
| 21 | Норлат авыл җирлеге |
| 22 | Ырынгы авыл җирлеге |
| 23 | Кырык Садак авыл җирлеге |
| 24 | Иске Суыксу авыл җирлеге |
| 25 | Иске Тинчәле авыл җирлеге |
| 26 | Тимбай авыл җирлеге |
| 27 | Күл Черкене авыл җирлеге |
| 28 | Килдураз авыл җирлеге |
| 29 | Чуаш Киштәге авыл җирлеге |
| 30 | Янтуган авыл җирлеге |
| 31 | Яшевка авыл җирлеге"; |

2) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Зур Фролово," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Адав-Толымбай авыл җирлеге чиге Түбән Наратбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 41, 42, 39 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, алга таба җиләк-җимеш питомнигын көньяк-көнбатыш чиге буйлап Затон күленә кадәр әйләнеп уза, шуннан соң күл буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң шул ук юнәлештә озын чокырның көньяк-көнбатыш кырые буйлап 150 м уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, күлне, сазлыкны, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м бара. Шуннан соң чик көньяк-көнбатышка таба 1,0 км урман авызы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка борыла һәм 150 м бара, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә 950 м "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, төньяк-көнбатышка таба 500 м әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка борыла һәм 453 м Зөя елгасы белән кисешкән ноктага кадәр уза, шушы елга агымы буенча 3,7 км өскә таба Адав-Толымбай, Түбән Наратбаш авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлангы авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) сигезенче һәм тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 5 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аксу авыл җирлеге Бик-Үти авыл җирлеге, Апас муниципаль районы һәм Чуаш Республикасы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аксу авыл җирлеге чиге Бик-Үти авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аксу, Бик-Үти авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ташкичү авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 400 м буага кадәр уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, 700 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, көньякка таба 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, аннары көньяк-көнчыгышка

таба 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап озын чокырга кадәр уза, төньяк-көнчыгышка борыла һәм 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң озын чокырны, ерынтыкны кисеп чыга һәм озын чокыр чиге буйлап буага кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км озын чокыр чиге буйлап "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталына кадәр бара, әлеге урман кварталын төньяк, көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап әйләнеп уза, шуннан соң 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык белән 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, аннары төньяк-көнчыгышка таба 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 490 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап озын чокыр очына кадәр уза, төньяк-көнбатышка таба 1,67 км озын чокырның көньяк чиге буйлап, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 28 м Бик-Үти – Ташкичү автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бола елгасына кадәр бара, 670 м әлеге елга агымы буенча өскә таба Аксу, Бик-Үти авыл җирлекләре һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Бик-Үти авылыннан 800 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) бишенче һәм алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 6 нчы кушымтада:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлши авыл җирлеге чиге Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әлши, Күшке һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуаш Киштәге авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 52 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 85 м Казан – Ульяновск автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 280 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 310 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньякка таба, 12 м көнчыгышка таба, Горький тимер юлы кырыендагы полосаны һәм Борындык – Боерган автомобиль юлы кырыендагы полосаны кисеп үтеп, 770 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньякка таба 40 м Борындык – Боерган автомобиль юлы кырыендагы полосаның көнчыгыш чиге буйлап, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 230 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,73 км урман полосасының көньяк чиге буйлап чираттагы урман полосасына кадәр бара, шушы урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,54 км төньяк-көнчыгышка һәм көньяк чиге буйлап 180 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә 1,37 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,04 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 220 м көньякка таба, 380 м көнчыгышка таба, 220 м көньяк-көнчыгышка таба, Зөя елгасын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт

бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы участок урманчылыгындагы 96 һәм 100 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Әлши, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Мәртле авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 76 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлши авыл җирлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә 79 (4в) нчы тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап Әлши, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 1,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 72 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) тугызынчы абзацта "Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге" сүзләрен "Әлши авыл җирлеге чиге" сүзләренә алмаштырырга, "Күшке, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре һәм Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Күшке һәм Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә һәм "Чуаш Киштәге авыл җирлеге, Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

д) унынчы абзацта "Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге" сүзләрен "Әлши авыл җирлеге чиге" сүзләренә алмаштырырга һәм "Күшке, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Күшке, Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

е) унберенче һәм уникенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

5) 8 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бик-Үти авыл җирлеге чиге Яңа Чәчкап авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба Лашчы елгасы агымы буенча аска таба Лашчы елгасына кибеп баручы инеш коя торган урынга кадәр бара, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба бара, шуннан соң озын чокырны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 6,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының көнбатыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,04 км авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инеш белән кисешкән җиргә кадәр бара, 2,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба Бик-Үти, Яңа Чәчкап һәм Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әхмәт авылыннан 1,4 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бик-Үти авыл җирлеге чиге Аксу авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аксу, Бик-Үти авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ташкичү авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 400 м буага кадәр уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, 700 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, көньякка таба 2,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, аннары көньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап озын чокырга кадәр уза, төньяк-көнчыгышка борыла һәм 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң озын чокырны, ерынтыкны кисеп чыга һәм озын чокыр чиге буйлап буага кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км озын чокыр чиге буйлап "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталына кадәр бара, әлеге урман кварталын төньяк, көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап әйләнеп уза, шуннан соң 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык белән 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, аннары төньяк-көнчыгышка таба 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 490 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап озын чокыр очына кадәр уза, төньяк-көнбатышка таба 1,67 км озын чокырның көньяк чиге буйлап, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 28 м Бик-Үти – Ташкичү автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бола елгасына кадәр бара, 670 м әлеге елга агымы буенча өскә таба Аксу, Бик-Үти авыл җирлекләре һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Бик-Үти авылыннан 800 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) тугызынчы – унберенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) уникенче абзацта "Бик-Үти авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге" сүзләрен "Бик-Үти авыл җирлеге чиге" сүзләренә һәм "Килдураз авыл җирлеге, Бик-Үти авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Бик-Үти, Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

д) унөченче абзацта "...нең басу аша кишәрлеге" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Адав-Толымбай," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Зур Фролово авыл җирлеге чиге Түбән Наратбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Фролово, Түбән Наратбаш авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлангы авылыннан 4,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 1,8 км урман полосасының көньяк чиге буйлап урман утыртмаларына кадәр уза, алга таба урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап ике инеш кушылган урынга кадәр уза, аннары инеш агымы буенча аска таба Тоша елгасына кадәр бара, 75 м әлеге елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 48 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 345 м урман массивы буйлап, 90 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 175 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 64 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа – Тәтеш автомобиль юлын кисеп үтеп, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 165 м чираттагы урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 365 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,32 км Зөя елгасының уң як яры буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба 14 м елга буенча бара, аннары 7,5 км әлеге елга агымы буенча аска таба Зур Фролово, Түбән Наратбаш һәм Күл Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күл Черкене авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) бишенче һәм унынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

7) 15 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацта "Күшке, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Күшке һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күшке авыл җирлеге чиге Әлши авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 52 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әлши, Күшке һәм Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуаш Киштәге авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

8) 16 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта ", Чүпрәле һәм Тәтеш муниципаль районнары белән" сүзләрен "һәм Тәтеш муниципаль районы белән" сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шәмәк авыл җирлеге чиге Әлши авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әлши, Күшке һәм Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуаш Киштәге авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 52 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 85 м Казан – Ульяновск автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 280 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 310 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньякка таба, 12 м көнчыгышка таба, Горький тимер юлы кырыендагы полосаны һәм Борындык – Боерган автомобиль юлы кырыендагы полосаны кисеп үтеп, 770 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньякка таба 40 м Борындык – Боерган автомобиль юлы кырыендагы полосаның көнчыгыш чиге буйлап, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 230 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,73 км урман полосасының көньяк чиге буйлап чираттагы урман полосасына кадәр бара, шушы урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,54 км төньяк-көнчыгышка һәм көньяк чиге буйлап 180 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә 1,37 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,04 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 220 м көньякка таба, 380 м көнчыгышка таба, 220 м көньяк-көнчыгышка таба, Зөя елгасын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы участок урманчылыгындагы 96 һәм 100 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 76 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) җиденче абзацта "Күшке, Шәмәк авыл җирлекләре һәм Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Чуаш Киштәге авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан" сүзләрен төшереп калдырырга;

г) сигезенче һәм тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

9) 20 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Зур Фролово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Фролово, Түбән Наратбаш авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлаңгы авылыннан 4,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 1,8 км урман полосасының көньяк чиге буйлап урман утыртмаларына кадәр уза, алга таба урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап ике инеш кушылган урынга кадәр уза, аннары инеш агымы буенча аска таба Тоша елгасына кадәр бара, 75 м

әлеге елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 48 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 345 м урман массивы буйлап, 90 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 175 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 64 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа – Тәтеш автомобиль юлын кисеп үтеп, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 165 м чираттагы урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 365 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,32 км Зөя елгасының уң як яры буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба 14 м елга буенча бара, аннары 7,5 км әлеге елга агымы буенча аска таба 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Адав-Толымбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Адав-Толымбай, Карлы һәм Түбән Наратбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 41, 42, 39 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, алга таба җиләк-җимеш питомнигын көньяк-көнбатыш чиге буйлап Затон күленә кадәр әйләнеп уза, шуннан соң күл буйлап 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң шул ук юнәлештә озын чокырның көньяк-көнбатыш кырые буйлап 150 м уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, күлне, сазлыкны, урман полосасын кисеп үтеп, 300 м бара. Шуннан соң чик көньяк-көнбатышка таба 1,0 км урман авызы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка борыла һәм 150 м бара, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә 950 м "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, төньяк-көнбатышка таба 500 м әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка борыла һәм 453 м Зөя елгасы белән кисешкән ноктага кадәр уза, шушы елга агымы буенча 3,7 км өскә таба Адав-Толымбай, Түбән Наратбаш авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлаңгы авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) унынчы – уникенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) унөченче абзацта "...нең басу аша кишәрлеге чиге" сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 22 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Аксу," сүзен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Бик-Үти авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка 1,6 км Лашчы елгасы агымы буенча аска таба Лашчы елгасына кибеп баручы инеш коя торган урынга кадәр бара, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба бара, шуннан соң озын чокырны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 6,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосаларының көнбатыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,04 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инеш белән кисешкән җиргә кадәр бара, 2,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба Бик-Үти, Яңа Чәчкап һәм Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әхмәт авылыннан 1,4 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

11) 30 нчы кушымтада:

а) дүртенче абзацта "Яңа Чәчкап, Килдураз авыл җирлекләре һәм Бик-Үти авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре" сүзләрен "Бик-Үти, Яңа Чәчкап һәм Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта "Бик-Үти авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Бик-Үти авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга, "Килдураз авыл җирлеге, Бик-Үти авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Бик-Үти, Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

12) 31 нче кушымтада:

а) бишенче абзацта "Күшке, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре һәм Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Күшке һәм Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта "Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Әлши авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә алмаштырырга, "Чуаш Киштәге авыл җирлеге, Әлши авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Әлши, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 1 июле
№ 46-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Чикләре әлеге Закон нигезендә үзгәрүче муниципаль берәмлекләрнең территорияләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

I - Әлши авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Шәмәк авыл жирлеге территориясе

II – Түбән Наратбаш авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Зур Фролово авыл жирлеге территориясе

III – Бик-Үти авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Аксу авыл жирлеге территориясе

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *70(5) - 67(6)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *67(6) - 6(7)* | - Чуаш Республикасы |
| *6(7) - 33(36)* | - Апас муниципаль районы |
| *33(36) - 75(4)* | - Тәтеш муниципаль районы |
| *75(4) - 79(4в)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *79(4в) - 78(4г)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *78(4г) - 70(5)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *71(5а) - 82(5б)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *82(5б) - 71(5а)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *6а (2 участок)* | - Чуаш Республикасы |